**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

26.01.2019

№ 65

**Россия Федерациясе Дәүләт советының «Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, шәһәр тирәлеге» юнәлеше буенча эш төркеме секретариатын оештыру турында**

Россия Федерациясе Дәүләт советының «Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, шәһәр тирәлеге» юнәлеше буенча эш төркеме төзелүгә бәйле рәвештә, аның нәтиҗәле эшчәнлеген һәм Россия Федерациясе Дәүләт советы утырышына материалларны үз вакытында әзерләү максатында:

1. Россия Федерациясе Дәүләт советының «Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, шәһәр тирәлеге» юнәлеше буенча эш төркеме секретариатын оештырырга.

2. Россия Федерациясе Дәүләт советының «Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, шәһәр тирәлеге» юнәлеше буенча эш төркеме секретариаты турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Татарстан Республикасы
Президентының
2019 елның « 26 »гыйнварындагы
65 номерлы боерыгына
1 нче кушымта

**Россия Федерациясе Дәүләт советының «Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, шәһәр тирәлеге» юнәлеше буенча эш төркеме секретариаты турында нигезләмә**

1. Россия Федерациясе Дәүләт советының «Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, шәһәр тирәлеге» юнәлеше буенча эш төркеме секретариаты (алга таба – секретариат) Россия Федерациясе Дәүләт советының «Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, шәһәр тирәлеге» юнәлеше буенча эш төркеме (алга таба – эш төркеме) эшчәнлеген тәэмин итү максатларында оештырыла.

2. Секретариат турыдан-туры эш төркеме җитәкчесенә буйсына.

3. Секретариат Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

4. Секретариатның төп функцияләре:

эш төркеменең утырышларын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру-техник чаралар эшләү һәм аларны үтәү;

эш төркеменә керүче документларны гомумиләштерү һәм алар буенча белешмәләр һәм аналитика материалларын әзерләү;

эш төркеме компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча йомгаклау бәяләмәләре һәм тәкъдимнәр әзерләүне оештыру;

эш төркемендә эш башкаруны оештыру.

5. Секретариат түбәндәгеләргә хокуклы:

дәүләт хакимияте органнарыннан, җәмәгать берләшмәләре һәм оешмалардан эш төркеменә йөкләнгән функцияләрне башкару өчен кирәкле материалларны билгеләнгән тәртиптә соратырга һәм алырга;

эш төркеме компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча экспертлык эшен һәм аналитик эш башкару өчен белгечләр җәлеп итәргә.

6. Секретариат түбәндәгеләргә бурычлы:

аның функцияләренә караган мәсьәләләр буенча эш төркеме карарларын үтәүне тәэмин итәргә;

үз эшчәнлеге йомгаклары буенча эш төркеме алдында хисап тотарга.

7. Секретариатның башлыгы булып эш төркеме җитәкчесе тарафыннан билгеләп куела торган секретариат җитәкчесе тора.

8. Секретариат җитәкчесе:

секретариатка йөкләнгән функцияләрнең үтәлүен тәэмин итеп, секретариат эшенә җитәкчелек итә;

дәүләт хакимияте органнары, җәмәгать берләшмәләре һәм оешмалары белән үзара хезмәттәшлектә секретариат вәкиле буларак эш йөртә;

эш төркеме җитәкчесенә секретариат эшен оештыруны камилләштерү турында тәкъдимнәр кертә;

секретариат функцияләрен гамәлгә ашыру белән бәйле хезмәт урынындагы язышуны имзалый.

9. Секретариат җитәкчесе һәм аның әгъзалары секретариатка йөкләнгән бурычларның үтәлеше өчен шәхсән җаваплы була.

---

Татарстан Республикасы
Президентының
2019 елның « 26 » гыйнварындагы
65 номерлы боерыгына
2 нче кушымта

**Россия Федерациясе Дәүләт советының «Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, шәһәр тирәлеге» юнәлеше буенча эш төркеме секретариаты составы**

| | |
|---|---|
| Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, секретариат җитәкчесе |
| Гафаров Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе, секретариат җитәкчесе урынбасары |
| Фәйзуллин Ирек Әнвәр улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры, секретариат җитәкчесе урынбасары |
| Гатиятов Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары |
| Насыйров Илдус Наил улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары |
| Нәфыйгин Альберт Илдар улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе |
| Сибгатуллин Илдар Нурзадә улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсе башлыгы |
| Фишман Наталия Львовна | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе |

| | |
|---|---|
| Фролов<br>Алексей Михайлович | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары |